КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 9 апрель г.Казань № 223

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 315 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 315 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 29 декабрь, 663 нче; 2006 ел, 2 май, 216 нчы; 2008 ел, 27 июнь, 449 нчы; 2009 ел, 13 июль, 491 нче; 2010 ел, 11 июнь, 465 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1035 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 29 август, 724 нче; 2011 ел, 29 август, 726 нчы; 2012 ел, 8 сентябрь, 761 нче; 2013 ел, 19 март, 190 нчы; 2014 ел, 1 февраль, 54 нче; 2014 ел,11 март, 150 нче; 2014 ел, 16 май, 325 нче; 2014 ел, 26 декабрь, 1042 нче; 2015 ел, 30 июнь, 472 нче; 2016 ел, 13 май, 301 нче; 2016 ел, 22 октябрь, 769 нчы; 2016 ел, 30 ноябрь, 880 нче; 2017 ел, 22 май, 295 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы турындагы нигезләмәгә, 3.3.1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәп, үзгәрешләр кертергә:

«ирекләләр (волонтерлык) тармагында дәүләт сәясәтен тормышка ашыруда катнашу;

милли һәм республика социаль-икътисадый, экологик, мәдәни һәм башка үзенчәлекләрне исәпкә алып, ирекләләргә (волонтерлыкка) ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны үз эченә алган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын (ярдәмче программаларны) эшләү һәм тормышка ашыру;

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, алар ведомствосындагы дәүләт учреждениеләренең ирекләләр (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар, ирекләләр (волонтерлык) оешмалары белән үзара хезмәттәшлеге тәртибен эшләү;

ирекләләр (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручыларга, ирекләләр (волонтерлык) оешмаларына ярдәм күрсәтү, шул исәптән аларның дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр һәм бүтән оешмалар, социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар, ирекләләргә (волонтерларга) оештыру, мәгълүмат, методик һәм бүтән ярдәм күрсәтүне тәэмин итүче дәүләт һәм учреждениеләр, ирекләләр (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручыларга һәм ирекләләр (волонтерлык) оешмалары белән үзара хезмәттәшлегендә;

ирекләләр (волонтерлык) эшчәнлеген популярлаштыру;

ирекләләргә (волонтерлыкка) ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны үз эченә алган муниципаль программаларга (ярдәмче программаларга) булышлык күрсәтү;

җирле үзидарә органнарын методик тәэмин итү һәм аларга муниципаль берәмлекләр территорияләрендә ирекләләрне (волонтерлыкны) үстерү буенча чараларны эшләүдә һәм тормышка ашыруда булышлык күрсәтү;

Министрлык каршында төзелә торган ирекләләр (волонтерлык) тармагында координацияләү һәм киңәшләшү органнарын формалаштыру.».

2. Бу карар 2018 елның 1 маеннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин